РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
НИЖНЕКАМСКИЙ
ГОРОДСКОЙ СОВЕТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

пр. Строителей, д. 12,
г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт,
Түбән Кама шәһәре, 423570

Тел./факс: (8555) 42-42-66. E-mail: Gorsovet.Nk@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 29 апреле № 25

2019-2021 елларга Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милекне хосусыйлаштыру фараз планын (программасын) үтәү турында хисапны раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Түбән Кама шәһәр Советының 2017 елның 15 сентябрендәге 22 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә ия булу, аннан файдалану һәм аның белән эш итү тәртибе турында» Нигезләмә нигезендә, Түбән Кама шәһәр Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама шәһәр Советының 2018 елның 19 декабрендәге 55 номерлы, 2019 елның 11 апрелендәге 20 номерлы карарлары белән расланган 2019-2021 елларга Түбән Кама муниципаль районы Түбән Кама шәһәренең муниципаль милеген хосусыйлаштыруның фараз планының (программасының) үтәлүе турында 2019 елга хисапны расларга (кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Түбән Кама шәһәр Советының бюджет сәясәте һәм икътисадый үсеш буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Түбән Кама шәһәре Мэры А.Р. Метшин

Түбән Кама шәһәр
Советының
2020 елның 29 апрелендәге
25 номерлы карарына
кушымта

2019-2021 елларга муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планын (программасын) үтәү турында 2019 елга хисап

Түбән Кама шәһәр Советының 2018 елның 19 декабрендәге 55 номерлы, 2019 елның 11 апрелендәге 20 номерлы карарлары белән расланган, муниципаль милекнең хосусыйлаштыру фараз планы (программасы) нигезендә 2019 елда хосусыйлаштырылырга тиешле объектлар исемлеге:

| т/с | Исеме | Урнашу урыны | Мәйданы, кв.м. | Хосусыйлаш-тыру вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлеге белән АХК бинасы | Түбән Кама шәһәре, Менделеев урамы, 46А йорт | 334,7 кв.м. 373+39 кв.м. | 2019 ел |
| 2 | 1001 номерлы торак булмаган бина | Түбән Кама шәһәре, Тынычлык пр., 38 йорт | 67,4 | 2019 ел |

2019 елда әлеге объектлар гамәлгә ашырылмаган.

Түбән Кама шәһәре
Мэры урынбасары

Э.Р. Долотказина